Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының унсигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

9 декабрь, 2021 ел № 130

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, гавами тыңлаулар беркетмәсен исәпкә алып һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2021 елның 3 декабрендәге бәяләмәсен исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен электрон чыганакта кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советына «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 28 августындагы 75/16 номерлы карарының үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов